КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 733

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-12 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» 2015 ел, 16 май, 345 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-12 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» 2015 ел, 16 май, 345 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенең 3 бүлегендәге 3.9 нчы пунктта «установленном порядке Президенту Республики Татарстан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенә 1 – 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 733 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планының
чаралар комплексы

| Стратегиянең төп эш юнәлешләре / проектлар | Төп чаралар исеме | Җаваплы үтәүче, үтәүчеләр | Гамәлгә ашыру чоры | Гамәлгә ашыру этаплары (I этап – 2016 – 2018 еллар; II этап – 2019 – 2021 еллар; III этап – 2022 – 2024 еллар; IV этап – 2025 – 2030 еллар) | Көтелә торган нәтиҗәләр | Гамәлгә ашыру территория-се | Программа (ярдәмче программа) исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Искәрмә:

1 Графа Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше стратегиясенә туры китереп тутырыла, Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше стратегиясе гамәлләренең һәм проектларының кыскача атамасын үз эченә ала.

2 Графа Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше стратегиясенең максатларын, бурычларын, төп юнәлешләрен һәм проектларын үтәү өчен министрлык яки ведомство тәкъдим иткән конкрет чаралар исемлеген үз эченә ала. Һәр чара өчен аерым юл өстәлә.

3 нче графада чараны гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары, муниципаль берәмлекләре һәм оешмалары исемнәре бар. Беренче булып җаваплы башкаручы күрсәтелә.

4 графада чараны гамәлгә ашыруның башлану һәм тәмамлау елы күрсәтелә.

5 графада чараларны гамәлгә ашыру этаплары күрсәтелә: I, II, III, IV.

6 графада чараны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре күрсәтелә (күрсәтелгән чара җибәрелгән объектның торышы яки индикаторның максатчан мәгънәсе).

7 графада чараны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы территориясе күрсәтелә.

8 графада чараны дәүләт программасына (ярдәмче программага) кертү варианты күрсәтелә (ярдәмче программаны дәүләт программасына кертмичә); гамәлдәге дәүләт программасына (ярдәмче программага) кертү; яңа дәүләт программасына (ярдәмче программага) һәм « / » билгесе аша дәүләт программасы (ярдәмче программа) исеме күрсәтелә.

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 733 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы комплексына төзәтмәләр кертү

| Стратегиянең төп эш юнәлешләре / проектлар | Төп чаралар исеме | Җаваплы үтәүче, үтәүчеләр | Гамәлгә ашыру чоры | Гамәлгә ашыру этаплары (I этап – 2016 – 2018 еллар; II этап – 2019 – 2021 еллар; III этап – 2022 – 2024 еллар; IV этап – 2025 – 2030 еллар) | Көтелә торган нәтиҗәләр | Гамәлгә ашыру территориясе | Программа (ярдәмче программа) исеме | Өстәмәләр, төзәтмәләр кертү яки төшереп калдыру кирәклеген нигезләү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Искәрмә:

1 графа Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше стратегиясенә туры китереп тутырыла, Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше стратегиясе гамәлләренең һәм проектларының кыскача атамасын үз эченә ала.

2 графа үз эченә түбәндәге исемлекне ала:

Татарстан Республикасын Социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планының гамәлдәге редакциясенә кертелгән чаралар планы (алга таба - Чаралар планы);

Чаралар планының гамәлдәге редакциясенә кертелгән чаралар формулировкасына министрлык яки ведомство тарафыннан тәкъдим ителә торган төзәтмәләр кертү;

Стратегия максатларын, бурычларын, төп юнәлешләрен һәм проектларын үтәү өчен кирәкле министрлык яки ведомство тарафыннан тәкъдим ителә торган яңа конкрет чаралар.

Һәр чара өчен аерым юл өстәлә.

3 - 8 графлар «Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы комплексы» дигән формада тутырыла.

9 графада төзәтмәләр кертү варианты күрсәтелә:

«Үзгәрешсез» – әлеге чарага төзәтмәләр кертү зарурлыгы булмаган очракта;

«Корректировка» - бу чараның формулировкасын, срокларын, җаваплы башкаручыларны, тормышка ашыру чорын, тормышка ашыру этапларын, көтелгән нәтиҗәне, тормышка ашыру территориясен яки дәүләт программасына кертүне үзгәртү кирәк булганда. Бу очракта чаралар планының гамәлдәге редакциясенә кертелгән чарадан соң киләсе юлда чараның корректлаштырылган формулировкасы өстәлә, 9 графада төзәтмәләр кертү нигезләре күрсәтелә;

«Яңа чара» – Чаралар планын Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең максатларын, бурычларын, төп юнәлешләрен һәм проектларын үтәү өчен кирәк булган яңа чара белән тулыландыру кирәк булган очракта. Бу очракта графада 9 өстәмә нигез күрсәтелә.

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенә 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 август, 733 нче карары редакциясендә)

Форма

Хисап чорында Татарстан Республикасыны социаль-икътисадый үстерү стратегиясен һәм Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын гамәлгә ашыруның барышы турында җыелма хисап

Хисап чорында максатчан индикаторларны үтәү

| Максатчан индикатор | Индикаторның планлы мәгънәсе | Индикаторның фактта мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| | | |

Искәрмә:

1 графа Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә туры китереп тутырыла, Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең төп индикаторлары атамаларын үз эченә ала.

2 графа Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыруның хисап чорында индикаторларның максатчан мәгънәләрен үз эченә ала.

3 графа хисап чорында факттагы күрсәткечләрне үз эченә ала. Факттагы мәгълүматлар булмаган очракта бәяләү күрсәткечләре күрсәтелә.

Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы чараларын тормышка ашыру

| Стратегиянең төп эш юнәлешләре / проектлар | Төп чаралар исеме | Җаваплы үтәүче, үтәүчеләр | Гамәлгә ашыру чоры | Гамәлгә ашыру этаплары (I этап – 2016 – 2018 еллар; II этап – 2019 – 2021 еллар; III этап – 2022 – 2024 еллар; IV этап – 2025 – 2030 еллар) | Көтелә торган нәтиҗәләр | Гамәлгә ашыру территориясе | Программа (ярдәмче программа) исеме | Чараны үтәү турында хисап |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Искәрмә:

1-8 графлар Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча гамәлдәге чаралар планы нигезендә тутырыла.

9 графада, 6 графта билгеләнгән нәтиҗәгә ирешү яки ирешмәүне күрсәтеп, чараны тормышка ашыруның ахыргы яки арадаш нәтиҗәләре китерелә.